# Татарстан Республикасы
# Тукай муниципаль районы
# « Биклән авыл җирлеге»
# муниципаль берәмлек Советы

№ 19/1 Биклән авылы «26» сентябрь 2018ел

« Биклән авылы жирлегендә Җирле референдум үткәрү инициативасы турында »

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «жирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Биклән авыл жирлеге Уставы нигезендә Биклән муниципаль берәмлек Советы ,

**Карар Кылды:**

1. «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Советы Биклән авыл жирлеге башкарма комитеты белән берлектә Биклән авыл жирлегендә жирле референдум үткәрү турында һәм референдум сорауларын түбәндәгечә тәкъдим итте:

«Сез 2019 елда Биклән авыл жирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз картайган гражданнар һәм студентлар өчен бер тапкыр түләнә торган түләүне киметергә һәм әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә ризамы һәм әлеге сумма түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереләчәкбез:

- Биклән авылында спорт мәйданчыгын төзекләндерү
- Биклән авылында видеокүзәтү урнаштыру
- Биклән авылында юлларны ремонтлау
- Биклән, Бакчасарай, Кызыл Юл авылларында урам утларын урнаштыру; »

2. Әлеге карарны Тукай территориаль сайлау комиссиясенә жибәрергә.
3. Әлеге карарны жирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе М.Ш.Сәхбеев